РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**КАРАР**
**РЕШЕНИЕ**

13 февраль 2015 ел                                                                                № 15-45

**«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы яшьләр парламенты турында нигезләмә турында»**

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнехановның Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы коллегиясенең 2014 елның 27 декабрендәге №ПР-344 номерлы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле хакимият органнары каршында иҗтимагый яшьләр парламентларын формалаштыру турындагы йөкләмәсен үтәү йөзеннән Буа муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Буа муниципаль районы Яшьләр парламенты турындагы нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны район газетасында Байрак (Знамя, Ялав) бастырып чыгарырга, Буа муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Буа муниципаль районы Советы Рәисе                                        А.К.Айзетуллов

Кушымта

# Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы яшьләр парламенты турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының яшьләр парламенты (алга таба-Яшьләр парламенты) муниципаль берәмлекнең яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен законнар белән җайга салу өлкәсендәге вәкиллекле органы эшчәнлегенә ярдәм итү, яшьләр проблемаларын хәл итү буенча тәкъдимнәр әзерләү, яшьләр өчен закон чыгару эшчәнлеге күнекмәләрен үзләштерүдә шартлар тудыру максатларында төзелә.

2. Яшьләр парламенты муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы каршындагы киңәшмә һәм консультатив орган булып тора һәм үз эшчәнлеген иҗтимагый нигездә яшьләр парламентының әлеге нигезләмәсенә һәм регламентына ярашлы рәвештә алып бара.

3. Яшьләр парламенты 5 елга төзелә.

## II. Яшьләр парламентының төп бурычлары

1. Яшьләрнең хокукларына һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылышлы муниципаль хокукый актларны карауга әзерләү буенча муниципаль берәмлек вәкиллекле органы комиссияләре эшчәнлегендә катнашу.

2. Муниципаль хокукый актлар проектларын эшләгәндә яшь гражданнарның инициативаларын тәкъдим итүдә ярдәм итү.

3. Яшьләрнең хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре өлкәсендә законнарны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү.

4. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә Яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыруга җәмәгатьчелек контролен гамәлгә ашыру.

5. Яшьләр арасында яшьләрнең хокукый культурасын күтәрүгә һәм актив гражданлык позициясен формалаштыруга юнәлдерелгән мәгърифәтчелек һәм аңлату эшләрен үткәрү.

## III. Яшьләр парламентын формалаштыру составы һәм тәртибе

1. Яшьләр парламенты әгъзалары булып Буа муниципаль районы территориясендә яшәүче, яшьләр парламенты составына сайланган вакытта 30 яшькә кадәрге Россия Федерациясе гражданнары була ала.

2. Яшьләр парламенты Татарстан Республикасының республика яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең район вәкиллекләреннән; Татарстан Республикасында Гомумроссия яшьләр иҗтимагый оешмаларының бүлекчәләреннән тора; Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советында тәкъдим ителгән сәяси партияләр, эшләүче һәм авыл яшьләре активистлары, шулай ук «ПолитЗавод» проектының муниципаль этабында катнашучылар (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы составына кермәгән).

3. 2 пунктта күрсәтелгән оешмалар үз утырышларында Яшьләр парламентына бер вәкил сайлыйлар һәм тиешле карарны парламент Советына җибәрәләр.

4. Яшьләр парламенты Советы әлеге парламент әгъзаларының Сан составын билгели һәм вәкаләтләрен раслый.

5. Яшьләр парламенты рәисе итеп Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы әгъзасы билгеләнә, ул аның составына әлеге районнан сайлана.

## IV. Яшьләр парламенты эшен оештыру

1. Яшьләр парламентының беренче утырышы узган чакырылыш Яшьләр парламенты Советы тәкъдиме буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органы тарафыннан чакырыла, ул беренче утырышның датасын билгели, Яшьләр парламенты әгъзаларын чакыра, чакырылганнар исемлеген һәм алып бару тәртибен билгели.

2. Яшьләр парламентының беренче утырышын әлеге парламент рәисе ача.

3. Беренче утырышта Яшьләр парламенты әгъзалары ачык тавыш бирү һәм гади күпчелек белән рәиснең ике урынбасарын, җаваплы секретарьны сайлыйлар, Яшьләр парламенты Советының Сан составын билгелиләр һәм аның әгъзаларын сайлыйлар, комиссияләр төзиләр.

4. Яшьләр парламенты утырышы, әгәр анда яшьләр парламенты әгъзаларының билгеләнгән санының өчтән ике өлеше булса, хокуклы.

5. Яшьләр парламенты үз эшчәнлеге юнәлешләре буенча тәкъдимнәр әзерли, кабул итә һәм аларны җирле үзидарә органнарына җибәрә.

6. Яшьләр парламентының карарлары һәм тәкъдимнәре, әгәр алар өчен Яшьләр парламентының билгеләнгән әгъзаларының күпчелеге тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

7. Яшьләр парламенты советын рәис җитәкли, аның вәкаләтләре Яшьләр парламенты регламенты белән билгеләнә.

8.Яшьләр парламенты Советы:

- Яшьләр парламенты һәм аның комиссияләре эшен оештыра һәм координацияли;
- Яшьләр парламентының эш регламентын эшли;
- Яшьләр парламентының чираттагы елга эш планнарын эшли һәм аларны Яшьләр парламентына раслау өчен тәкъдим итә;
- Яшьләр парламенты регламентына ярашлы рәвештә башка вәкаләтләр башкара.

9. Яшьләр парламенты Советы тәкъдиме буенча Яшьләр парламенты әгъзалары муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының вәкиллекле органнары депутатларына иҗтимагый нигездә ярдәмчеләр сыйфатында тәкъдим ителергә мөмкин.

10. Яшьләр парламенты комиссияләре эшне оештыралар һәм яшьләр парламенты утырышларында карау өчен үз функцияләренә ярашлы рәвештә тәкъдимнәр һәм карарлар проектларын әзерлиләр.

11. Яшьләр парламенты эшендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары, шулай ук чакыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары җитәкчеләре, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органнары депутатлары, муниципаль берәмлекнең башкарма комитетлары вәкилләре, Татарстан Республикасы территориясендә эш итүче сәяси партияләр һәм иҗтимагый оешмалар җитәкчеләре катнаша ала.

12. Яшьләр парламенты утырышларын оештыру-техник тәэмин итү муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.